РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» октябрь 2019 г. г. Альметьевск № 329

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 27 июлендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында Әлмәт шәһәр Советы тәкъдимен кабул итү хакында» 189 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 6 маендагы 468 нчы номерлы карары белән расланган вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибе нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 27 июлендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре вәкаләтләренең бер елешен тапшыру турында Әлмәт шәһәр Советы тәкъдимен кабул итү хакында» 189 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары проектын эшләргә һәм карап тикшерүгә тапшырырга».

2. Карарга 1 нчы кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (1нче кушымта).

Зак. № 3775

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Салахов И.Р.).

Муниципаль район башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының
2019 елның 25 октябрендәге
329 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре башкарма комитеты вәкаләтләренең бер елешен тапшыру турында килешү

«___»_________ 2019 ел Әлмәт шәһәре

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы һәм Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты турындагы нигезләмә нигезендә эш итүче Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе __________________________ йезендә, алга таба «район башкарма комитеты» дип аталучы, икенче яктан, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре башкарма комитеты турындагы нигезләмә нигезендә эш итүче Әлмәт шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе __________________________йезендә, «яклар» дип аталучылар әлеге килешүне тезеделәр:

1. Килешү предметы

Әлеге килешүнең предметы булып Әлмәт районы һәм шәһәре территориясендә күмү урыннарын карап тоту өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү буенча Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты вәкаләтләрен Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре башкарма комитетына тапшыру тора.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Әлмәт шәһәре башкарма комитеты Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетына тәкъдим итә:

- әлеге килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары һәм матди ресурслар (алга таба-вәкаләтләр);

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен кирәкле мәгълүмат.

2.2. Әлмәт шәһәре башкарма комитеты хокуклы:

- Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты вәкаләтләренең үтәлешен, шулай ук әлеге килешүнең 5.1-5.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә бирелгән финанс чараларының һәм матди рәсурсларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

- район башкарма комитетыннан әлеге килешү предметына кагылышлы мәгълүматны алырга.

2.3. Район башкарма комитеты бурычлы:

- закон таләпләре нигезендә вәкаләтләрне тормышка ашыру, шул исәптән Әлмәт шәһәре башкарма комитеты тарафыннан бирелгән финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан максатчан файдалануны тәэмин итү, бары тик вәкаләтләрне башкару өчен генә;

- Әлмәт шәһәре башкарма комитетына вәкаләтләрнең үтәлеше турында квартал саен хисаплар, аерым соратулар буенча килешү предметына кагылышлы башка мәгълүматны тапшырырга.

2.4. Район башкарма комитеты хокуклы:

- Әлмәт шәһәре башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырыла торган финанс чараларын һәм матди ресурсларны алырга һәм кулланырга;

- Әлмәт шәһәре башкарма комитетыннан вәкаләтләрне башкару өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен закон нигезендә өстәмә рәвештә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдаланырга.

3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен
финанс чараларын бирү тәртибе

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен кирәкле финанс чаралары бюджет законнары нигезендә бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру ечен бирелә торган финанс чаралары күләме Әлмәт муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты турында карары белән билгеләнә.

3.3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары квартал саен тигез өлешләр белән күчерелә.

3.4. Район башкарма комитеты тарафыннан финанс чаралары максатчан файдаланмаган очракта, алар Әлмәт шәһәре башкарма комитеты таләбе буенча ун кенлек срокта Әлмәт шәһәре бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

4. Матди ресурсларны тапшыру тәртибе

4.1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 10 елешенең 5 пункты нигезендә, муниципаль районның вәкиллекле органы карары нигезендә кабул ителгән әлеге килешүгә кул куелганнан соң утыз кен эчендә Әлмәт шәһәре башкарма комитеты муниципаль милекне бушлай файдалану килешүе нигезендә вәкаләтләрне район башкарма комитеты тапшыра.

4.2. Әлеге килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән түләүсез файдалану шартнамәсе вакытлы булып тора һәм әлеге килешүнең гамәлдә булу срогына тезелә.

4.3. Әлеге килешүнең 4.1 пункты нигезендә тапшырылган матди ресурслардан файдалану тәртибе түләүсез файдалану килешүе белән билгеләнә һәм аның мөһим шарты булып тора.

5. Вәкаләтләрнең үтәлешен контрольдә тоту

5.1. Әлмәт шәһәре башкарма комитеты вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, район башкарма комитетыннан тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүматны сорый. Әлмәт шәһәре башкарма комитеты соратулары буенча район башкарма мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керү мемкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

5.2. Отчетларның формасы һәм аларны бирү тәртибе район башкарма комитетының хокукый актлары белән билгеләнә.

5.3. Тапшырылган финанс чараларын һәм матди ресурсларны сарыф итүне контрольдә тоту Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Контроль-хисап палатасы һәм район башкарма комитеты тарафыннан, шул исәптән Әлмәт шәһәре башкарма комитеты соравы буенча да башкарыла.

6. Килешүнең гамәлдә булу срогы

6.1. Килешү рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

6.2. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы 2019 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6.3. Килешү яклары аны езү турында килешүнең 6.1 пунктында каралганча, срогы чыкканчы яклар тарафыннан 30 көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителмәсә, килешү еч елга озайтылган дип санала.

7. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе

7.1. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- яклар килешүе буенча;
- якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, бер яклы тәртиптә.

7.2. Әлеге килешүне өзү турында хәбәрнамә башка якка язма рәвештә аның гамәлдә булу вакыты тәгәлләнергә тиешле датага кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

7.3. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, район башкарма комитеты Әлмәт шәһәре башкарма комитетына вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән, ләкин файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди ресурсларны кире кайтара.

8. Якларның җаваплылыгы

8.1. Әлеге килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү гамәлдәге законнарда каралганча җаваплылыкка нигез булырга мөмкин.

8.2. Әлеге килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле як икенче якка 3.2 пунктта каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

8.3. Штраф түләү якларны әлеге килешү буенча йөкләмәләрне киләчәктә үтәүдән азат итми.

9. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

Әлеге килешүне үтәү белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары үткәрү юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр яисә килештерү процедураларын үткәрү юлы белән хәл итү мөмкин булмаганда, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

10. Йомгаклау нигезләмәсе

10.1. Килешүгә кертелгән барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

10.2. Килешү ике нөсхәдә, һәр як өчен берәр несхәдә төзелде.

11. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе<br>______________________________ |

Муниципаль район башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»